


Татар антропонимик системасында кушаматлар, этномәдәни берәмлеге буларак, исем йортvче белән исем бирvче арасындагы унай яки тискәре монәсәбәтне чагылдыра. Кушамат («кушама» (кушма) + «ат» (исем) сvзләре кушылу юлы белән ясалган) кешенен рәсми, топ исеменә остәмә ат бирә.

Кушамат терминынын икенче олешендә борынгы торки телдән килгән «ат» сvзе булуы анын тамырлары тирәндә икәнлекне һәм топ исемгә остә-мә рәвештә элек-электән кулланылуны раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарган, ягъни кеше исеменә остәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырган. Орхон-Енисей язмаларында, М.Кашгарыйнын «Диване логатет торк» хезмәтендә исем белән бергә кушамат та аерым функция vти. М.Кашгарыйнын әлеге сvзлегендә «at» сvзенен беренче мәгънәсе «исем» дип кvрсәтелсә, икенче мәгънәсе – «кушамат» (Махмут ал-Кашгари, с.112). Бvген дә кайбер татарларыбыз «Атын ничек?» дип сорыйлар.
Кушамат – кешегә анын vзенчәлекле сыйфатларын яки жәмгыятьтәге урынын ачу максатында жәмгыять яки кешеләр тарафыннан бирелгән официаль булмаган исем. Кайвакыт кушаматлар рәсми тос алып, исем, фамилия, ата исеме белән бергә дә килергә момкин: Пётр Беренче, Боек Патшабикә һәм башкалар.
Борынгы чорларда кушамат нәсел тамгасы, нәсел-ыруг атамасы булып та йоргән. Мәсәлән, регионыбыз авылларынын һәркайсында диярлек «муллалар, комиссарлар, толкеләр, бvреләр, куяннар...» һәм башка кушаматлар бар. Я булмаса, «тунганнар, кыргыйлар...» кебек vзенчәлеккә дә ия булалар.
Шәхси кушаматлар исә, теге яки бу кешенен торле сыйфатларына нигез-ләнгән метафорик мәгънәгә ия булып, чыгышлары белән реаль чынбарлыкка тыгыз бәйле була. Балага исемне тугач та әти-әнисе бирсә, кушаматны тор-мышынын торле этабында коллектив, жәмгыять куша. Мәсәлән, Ринат Харрис та vзенен шигырендә Һади Такташнын Сыркыдысында билгеле булган Адюк исеме белән эндәшә. Темник ягы татарларын бvген ойрәнгән Марат Сафаров белән Ринат Абянов vзләренен ВКонтакте

битләрендә болай дип язганнар: ««Казан» журналынын декабрь саны Татарстаннын кvренекле мәдәният эшлеклеләренә багышланган. Алар арасында шагыйрь Һади Такташ яки Адюк абзи да бар, аны шулай туган авылы Сыркыдыда жылы һәм дулкынландыргыч итеп атаганнар...» Әйтеп китик, Торбеево районындагы татар авылларында тосле, Краснослабодск, Темников, Кадошкино районы татар авылларында да, Ельники районы Акчеево-Кvгештә дә еш яратып Мокамай - Мохәммәтжан, Һади - Адюк, Абидулла – Абидюк, Загидулла – Загидюк, Ханёк – Хәнифә, Халёк – Халифә, Фәридә - Фәрёк, Мәдёк - Мәдинә, Шәрифә-Шәрюк... дип йортәләр. Мордовиянен конбатыш районнарында бу кvренеш шактый кин таралган була. Хәтта XX гасыр башында яшәгән кешеләр, авылдашларын искә алганда, кушаматлары белән сагыналар: Айнулла – Айню, Ләтифә апа - Ләтёк тәтәй,  Золәйха – Зеләйлюк, Мәдинә – Мәдёк, Разыя – Разай һәм башкалар. Кушаматлар телнен этнокультур ти-рәлеген гәvдәләндерәләр, матур әдә-бият әсәрендә геройларнын характер vсеш-vзгәрешен дә ачарга ярдәм итәләр. Гомуммән, илебезнен тарихи язмаларында, әдәби әсәрләрендә бу кvренеш шактый кин чагылыш тапкан һәм бvген дә яши.

**Наилә НАСЫРОВА**